ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

08.11.2024 | д. Канаш | - 3 номерлы

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Югары Ослан муниципаль районының Канаш авылы җирлегенең
Канаш авылы гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 20 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге гражданнары арасында үзара салым җыю мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Канаш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү
«ӘЙЕ» «ЮК»
3. Гражданнар җыенын Канаш авылы, Үзәк урамы, 32 йорт янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.
4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков